# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 4** **11.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Үрәзмәт авыл җирлеге составына керүче
Чишмә торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Чишмә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 3600 (өч мең алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Чишмә авылы Садовая һәм Урожайнаяурамнарындагы юл ремонты;
- Чишмәдә урамнарны һәм керү юлларын җәйге һәм кышкы карап тоту;
- Чишмә авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Яңа Усы авылы, Совет урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы А.Г. Закирянов